СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.10.2019 Баулы шәһәре № 226

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның 12 маенда
кабул ителгән 108нче «Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль
районының Иҗтимагый советы
турында Нигезләмәне раслау хакында»гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 15 маенда кабул ителгән 395нче «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендә кабул ителгән 906нчы номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында»гы карары белән расланган типлаштырылган «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 12 маенда кабул ителгән 108нче карары белән расланган (Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 31 августында кабул ителгән карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) «Баулы муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Иҗтимагый советны формалаштыру тәртибе» дип исемләнгән 4нче бүлектә «Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла» пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-этик нормаларны тупас бозуы өчен – утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелеге тавышы белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

- Иҗтимагый совет утырышларында җитди сәбәпсез системалы (өч тапкырдан артык) катнашмау;

- Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары күрсәтмәләрен нигезле сәбәпсез системалы (ике тапкырдан артык) үтәмәү;

- Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнү;

- чит ил гражданлыгы (подданлыгы) алу;

- Россия Федерациясе гражданлыгын туктату.».

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин